ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.02.2019 Алексеевск ш.т.б. № 56

**«2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында**

«Россия Федерациясендә 2016-2020 елларга Физик культура һәм спортны үстерү» федераль максатчан программасы, «2014-2021 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасы нигезендә,

**крар бирәм:**

1. "2019-2021 елларга Алексеевск муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль Программасын (алга таба – Программа) кушымта нигезендә расларга.

2. Шәһәр һәм авыл җирлекләре Башкарма комитетлары җитәкчеләренә, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә (Сөләйманов Р. Б.), Башкарма комитетның мәдәният бүлегенә (Соловьев А. Г.), «Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ (Гыйләҗев Д. А.) расланган Программаның үтәлешен тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

3. Финанс-бюджет палатасына (Леденцов О. Н.) «мәгариф», «мәдәният», «яшьләр сәясәте» һәм «спорт» тармаклары буенча каралган бюджет акчаларыннан Программа чараларын гамәлгә ашыру өчен акча бүлеп бирүне күздә тотарга.

4. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://alekseevskiy.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча бастырып чыгарырга:

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Н.П. Чуринга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**

Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
07.02.2019 № 56
карарына кушымта

**2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү Программасы**

| | |
|---|---|
| **Программаның Исеме** | 2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү Программасы |
| **Программаны төзү өчен нигез** | - «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы;<br>- «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>- «Россия Федерациясендә 2016-2020 елларга Физик культура һәм спортны үстерү» федераль максатчан программасы;<br>- 2011-2013 елларга Татарстан Республикасында инвалид калун профилактикалау һәм инвалидларны реабилитацияләү системасын үстерү концепциясе;<br>- «2014-2021 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» турындагы дәүләт программасы |
| **Программаны төзүчеләр** | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге. |
| **Программаның заказчысы** | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты |
| **Программаның төп максатлары һәм бурычлары** | Максатлар:<br>- физик культура, спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру;<br>- физик культура һәм спорт өлкәсендә идарә итү системасын камилләштерү, тармакара координацияләү;<br>- Алексеевск районы спортчыларының республика, бөтенроссия һәм халыкара ярышларда уңышлы катнашуын тәэмин итү;<br>- физик культура хәрәкәтенең массачыллыгын арттыру.<br>Бурычлар:<br>- физик культура һәм спорт өлкәсендә законнар үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итү;<br>- физкультура-спорт һәм туристлык эшчәнлеген финанс, матди-техник һәм кадрлар белән тәэмин итү механизмнарын камилләштерү; |

| | |
|---|---|
| | - физик активлыкны һәм сәламәт яшәү рәвешен системалы пропагандалауны оештыру, халыкның барлык категорияләре арасында, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән затлар арасында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләрнең өлешен арттыру;<br>- физкультура-спорт һәм туристлык оешмаларын үстерү, спортның яңа төрләрен үстерү;<br>- физкультура-спорт оешмаларына дәүләт ярдәме күрсәтү;<br>- массакүләм разрядлы спортчыларны әзерләү;<br>- физкультура-спорт юнәлешендә югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә булышлык күрсәтү. |
| **Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары** | Программа 2019-2021 еллар дәвамында тормышка ашырылачак |
| **Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары** | Программаны финанслау Алексеевск муниципаль районы бюджеты, бюджеттан тыш акчалар, республика бюджеты акчалары хисабына җирле бюджетка билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелгән күләмнәрдә гамәлгә ашырылачак:<br>2019 ел – 285 мең сум<br>2020 ел – 285 мең сум<br>2021 ел – 285 мең сум<br>республика бюджеты:<br>2019 ел - 420.0 мең сум (спортинвентарь)<br>2020 ел - 420,0 мең сум (спортинвентарь)<br>2021ел - 420,0 мең сум (спортинвентарь) |
| **Программаны тормышка ашыручылар** | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге;<br>МКУ «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге»;<br>өстәмә белем бирү учреждениеләре;<br>МУ «Алексеевск районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге»;<br>Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Алексеевск районы буенча бүлеге;<br>Россия Эчке эшләр министрлыгының Алексеевск муниципаль районы буенча бүлеге;<br>Алексеевск муниципаль районы предприятиеләренең һәм оешмаларының барлык милек рәвешләрендәге физик культура коллективлары. |
| **Программаны тормышка** | - физик культура, спорт һәм туризм белән шөгыльләнүгә массакүләм җәлеп итү юлы белән сәламәт яшәү рәвешен |

| | |
|---|---|
| **ашыруның көтелгән нәтиҗәләре** | формалаштыру һәм район халкының төрле төркемнәре сәламәтлеген ныгыту;<br>- Алексеевск муниципаль районы спортчыларының республика бөтенроссия һәм халыкара ярышларда казанышлары үсеше;<br>- түләүле физкультура-спорт хезмәтләренең күләмен һәм сыйфатын арттыру;<br>- армиягә кадәрге һәм хәрби хезмәткә чакыру яшенә җиткән егетләрнең физик әзерлекләрен яхшырту;<br>- халыкның төрле төркемнәре арасында, җәмгыятьтәге тәртипсезлекне кисәтү буенча, физик культура һәм спортның ролен арттыру;<br>- мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне физик тернәкләндерү һәм социаль җайлаштыру. |

## 1. Кереш

2019-2021 елларга Алексеевск муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү программасы (алга таба-Программа) сәламәтлекне ныгытуны, физик активлыкны арттыруны һәм халыкның барлык яшь төркемнәренең әзерлекле булуын, тулы канлы ял итү һәм сәламәт ял итү өчен шартлар тудыруны, спорт резервын әзерләүне һәм район спортчыларының республика, Россия һәм халыкара спорт ареналарында уңышлы чыгыш ясауларын күз алдында тота.

## 2. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программалы методлар белән хәл итү кирәклеген нигезләү

Берничә ел дәвамында авырулар санының артуы һәм халыкның яшәү дәвамлылыгы кимү, травматизм дәрәҗәсе күтәрелү, инвалидлар санының арту тенденцияләре күзәтелә. Гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алган елларда укучыларның сәламәтлек дәрәҗәсе 4-5 тапкырга кими. Сәламәтлекләре буенча хәрби хезмәткә яраклы булмаган егетләр саны елдан-ел арта бара, тәмәке тартуга, спиртлы эчемлекләр һәм наркотиклар куллануга һәвәсләнгән балалар һәм яшүсмерләр саны күбәя. Соңгы тикшеренүләр мәгълүматлары буенча, укучылар җиде яшьтән үк тәмәке тарта башлый. Эшкә яраклы халык арасында үлүчеләр санының артуы да борчу тудыра. Физик культура үзенчәлекле эшчәнлек буларак, хәрәкәтләнү сәләтен һәм күнекмәләрен формалаштыруга, кешенең физик кондицияләрен арттыруга, сәламәтлекне саклау һәм ныгытуга, шәхеснең гармонияле үсешенә юнәлдерелгән, кешегә тәэсир итүнең бөтен комплексын кулланырга мөмкинлек бирүче көчле сәламәтләндерү факторы: эчке халәтне формалаштыру һәм сәламәт яшәү рәвеше алып барырга теләүдән алып, кешене зарарлы гадәтләрдән баш тартуга стимуллаштыручы уңай шартлар тудыруга кадәр.

Физик культура һәм туризмны үстерү буенча район программасын эшләү һәм тормышка ашыруның актуальлеге яшьләр, иҗтимагый һәм спорт оешмалары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру гына түгел, ә сәламәт буын формалаштыру

проблемаларын комплексЛы хәл итү өчен дә кирәк. Районда спортны, физик культураны үстерү буенча эш мәгариф учреждениеләре, балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе аша башкарыла (яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге). Соңгы вакытта, җитәкче органнарының җентекле игътибары һәм районда спортны үстерүгә юнәлдерелгән төгәл координацион эш нәтиҗәсендә спорт белән шөгыльләнүчеләр санының тотрыклы үсеш тенденциясе күзәтелә.

Бу эштә катнашучы оешмаларның тренер-педагогик составларына стимуллаштыру, финанс һәм мораль ярдәм нәтиҗәсендә үз квалификацияләрен күтәрү, яңа эш ысулларын эшләү, секцияләрнең һәм бүлекләрнең матди-техник базасын ныгыту мөмкинлеге бирелде.

Бүгенге көндә спорт-массакүләм эшләр үткәрү өчен булган махсус биналарны ремонтлау һәм реконструкцияләү мәсьәләләре кискен тора; яшәү урыны буенча район спорт клублары челтәрен булдыру һәм камилләштерү, аларның матди базасын ныгыту, яшүсмерләрдә һәм яшьләрдә сәламәт яшәү рәвешенә омтылыш тәрбияләүнең заманча таләпләре нигезендә төрле дәрәҗәдәге мәгариф учреждениеләре эшенең яңа формаларын һәм методларын гамәлгә кертү, иҗтимагый файдалы хезмәт аша муллыкка ирешү, патриотлык һәм гражданлык хисләрен спорт белән даими шөгыльләнү аша үстерү таләп ителә.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып һәм яшьләр безнең район халкының күп өлешен тәшкил итүен исәпкә алып, спорт үсеше мәсьәләләрен хәл итү тиешле дәүләт һәм муниципаль органнар һәм иҗтимагый оешмалар тарафыннан комплекслы системалы якын килүне таләп итә. Районның яшьләр сәясәтен тормышка ашыру тәҗрибәсе һәм яңа эшләнмәләре булган яшьләрнең хәле әлеге программаны эшләү һәм кабул итү зарурлыгына ышандыра.

## 3. Программаның төп максатлары һәм бурычлары

***Максатлар:***

- физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру;
- физик культура һәм спорт өлкәсендә идарә итү системасын камилләштерү, тармакара координацияләү;
- Алексеевск районы спортчыларының республика, бөтенроссия һәм халыкара ярышларда уңышлы катнашуын тәэмин итү;
- физкультура хәрәкәтенең массачыллыгын арттыру.

***Бурычлар:***

- физик культура, спорт һәм туризм өлкәсендә законнар үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итү;
- физкультура-спорт эшчәнлеген финанс, матди-техник һәм кадрлар белән тәэмин итү механизмнарын камилләштерү;
- физик активлыкны һәм сәламәт яшәү рәвешен системалы пропагандалауны оештыру, халыкның барлык категорияләре арасында, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән затлар арасында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләрнең өлешен арттыру;
- физкультура-спорт оешмаларын үстерү, спортның яңа төрләрен үстерү;
- физкультура-спорт эшен үстерүдә иҗтимагый оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү;
- массакүләм разрядлы спортчыларны әзерләү, сәләтле яшь спортчылар белән

индивидуаль эш алып баруны көчәйтү;

- укыту-тренировка процессының сыйфатын арттыру;
- физкультура-спорт һәм туристлык профиле буенча югары квалификацияле белгечләрне әзерләүгә булышлык күрсәтү.

## 4. Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары

Программа 2019-2021 елларда тормышка ашырылачак.

## 5. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программа физик культура һәм спорт өлкәсендә оештыру, норматив, фәнни-методик, мәгълүмати һәм кадрлар мәсьәләләрен хәл итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы булып тора. Әлеге проблемаларны хәл итүдә муниципаль хакимият органнары һәм кызыксынган оешмаларның киң даирәсе катнашырга тиеш. Шуңа бәйле рәвештә программаны гамәлгә ашыру механизмы түбәндәгеләрне күз алдында тота: кызыксынган органнар һәм оешмаларның программа чараларын башкаручыларның гамәлләрен даими координацияләү; Программа чараларын тормышка ашыру нәтиҗәлелеге мониторингы; программа чараларын гамәлгә ашыруда спорт оешмаларының ролен арттыру; массакүләм физкультура-сәламәтләндерү эшенең, югары класслы спортчыларын һәм спорт резервын әзерләүнең нәтиҗәле методикаларын һәм технологияләрен эшләү һәм гамәлгә кертү.

## 6. Программаны финанс белән тәэмин итү

Программаны финанслау Алексеевск муниципаль районы бюджеты, бюджеттан тыш акчалар, шулай ук билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелгән республика бюджеты акчалары хисабына гамәлгә ашырылачак.

| № | Чараның исеме | Финанс чыгымнары (җирле бюджет) мең сумнар | | | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2019 | 2020 | 2021 | |
| 1 | Матди-техник базаны ныгыту. | 50,0 | 50,0 | 50,0 | 150,0 |
| 2 | «Татарстан чаңгы юлы», «Милләтләр кроссы» массакүләм район ярышлары | 30,0 | 30,0 | 30,0 | 90,0 |
| 3 | Предприятие һәм оешма хезмәткәрләренең 10 төр буенча район Спартакиадасы | 91,5 | 91,5 | 91,5 | 274,5 |
| 4 | Спорт төрләре буенча район беренчелекләре: футбол, хоккей, өстәл теннисы, көрәш, бадминтон, милли көрәш, шахмат, чаңгы ярышлары, йөзү, бокс, волейбол, баскетбол. | 300,0 | 300,0 | 300,0 | 900,0 |
| 5 | Спорт төрләре буенча җыелма командаларның Республика, Татарстан беренчелекләрендә, бөтенроссия | 380,0 | 380,0 | 380,0 | 1140,0 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | турнирларында катнашуы. | | | | |
| 6 | ФК һәм спорт өлкәсе белгечләренең квалификациясен күтәрү курсларында, республика семинар-киңәшмәләрендә катнашуы | 41,0 | 41,0 | 41,0 | 123,0 |
| | БАРЛЫГЫ: | 892,5 | 892,5 | 892,5 | 2677,5 |

| № | Чараның исеме | Финанс чыгымнары (җирле бюджет) мең сумнар | | | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2019 | 2020 | 2021 | |
| 1 | Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбенең матди-техник базасын ныгыту. | 420,0 | 420,0 | 420,0 | 1260,0 |
| | БАРЛЫГЫ: | 420,0 | 420,0 | 420,0 | 1260,0 |

Программаны тормышка ашыру өчен каралган акчаларның күләме, үз акчалары хисабына да, Алексеевск муниципаль районы бюджетына керә торган бюджетара трансфертлар хисабына да, Алексеевск муниципаль районы бюджетының керем өлешен үтәүгә бәйле рәвештә дә, үзгәрергә мөмкин.

## 6. Программаны гамәлгә ашыруның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны тормышка ашыруның социаль-икътисади нәтиҗәлелеге район халкын физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итүне арттыруда; район спортчыларының республика һәм бөтенроссия ярышларындагы нәтиҗәләрен арттыу; район халкының төрле төркемнәре арасында авыручылар санының кимүе; армиягә кадәрге һәм хәрби хезмәткә чакыру яшенә җиткән егетләрнең физик әзерлеген яхшырту; физик культура-спорт һәм туристлык хезмәтләренең, шул исәптән түләүлеләренең дә һәркем өчен уңайлылыгын, төрлелеген һәм сыйфатын күтәрү; мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне физик тернәкләндерү һәм социаль адаптацияләү өчен мөмкинлекләрне киңәйтү; ял итүнең актив формалары буенча район халкының ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерү.

**2019-2021 елларга Алексеевск муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү чаралары**

| № | Чаралар эчтәлеге | Үтәлеш вакыты | Үтәү өчен җаваплылар |
|---|---|---|---|
| | **1. Оештыру чаралары** | | |
| 1.1 | Алекеевск муниципаль районы Советы утырышларында физик культура һәм спортны үстерү мәсьәләләрен системалы рәвештә карап тикшерү | 2019-2021еллар | РС, ЯЭСТБ |
| 1.2 | Авыл җирлекләре, предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр арасында физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм туристлык эшен иң яхшы оештыручыга район бәйгеләрен оештыру һәм үткәрү | 2019-2021еллар | ЯЭСТБ, МәгБ |
| 1.3 | Ел саен физкультура-сәламәтләндерү, спорт ярышларының бердәм программасын эшләү һәм тормышка ашыру (район спорт ярышлары, предприятиеләр һәм оешмалар арасында Спартакиада, республика ярышларында катнашу, иң яхшы спортчыларны бүләкләү һәм башкалар.) | 2019-2021еллар | ЯЭСТБ |
| 1.4 | Милли спорт төрләре буенча ярышлар оештыру (татар-башкорт милли көрәше, «Көрәш») | 2019-2021еллар | ЯЭСТБ |
| 1.5 | Мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр белән физкультура-сәламәтләндерү эшен оештыру | 2019-2021еллар | ЯЭСТБ |
| 1.6 | Эчке эшләр органнарында исәптә торучы балигъ булмаганнарны физкультура-сәламәтләндерү, спорт, туристлык секцияләрендә шөгыльләнүгә җәлеп итү | даими | МәгБ, ЯЭСТБ, ББК |
| 1.7 | Мәктәпкәчә, гомуми белем бирү оешмаларында һәм Алексеевск аграр көллиятендә куллану өчен физик культура һәм спортны үстерү эшен яхшырту буенча фәнни-теоретик һәм гамәли тәҗрибәне исәпкә алып методик кулланмалар эшләү | даими | МәгБ, ЯЭСТБ |
| 1.8 | Районның мәктәпкәчә һәм белем бирү оешмаларында һәм Алексеевск аграр көллиятендә спорт һәм туристлык | 2019-2021еллар | МәгБ, ЯЭСТБ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | тематикасына бәйге нигезләмәләрен төзү һәм аларны үткәрү | | |
| 1.9 | Физкультура-спорт һәм туристлык чараларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын контрольдә тоту | даими | ЯЭСТБ, МәгБ |
| 1.10 | Физкультура-спорт һәм туристлык корылмаларын эксплуатацияләүнең куркынычсыз шартларын тәэмин итү буенча системалы тикшерүләр оештыру | даими | ЯЭСТБ, МәгБ |
| 1.11 | Ишегалдындагы спорт мәйданчыкларын җиһазлау һәм оешмаларга беркетү | даими | РБК |
| 1.12 | Физкультура-спорт корылмаларын спорт җиһазлары һәм кирәк-яраклары белән җиһазлау | даими | РБК |
| 1.13 | Массакүләм мәгълүмат чараларында физик культура һәм спорт белән актив шөгыльләнү турында хәбәрләрне даими яктырту | даими | ЯЭСТБ,<br>«Заря», «Таң» газетасы |
| 1.14 | Югары спорт нәтиҗәләренә ирешкән спортчыларны һәм тренерларны бүләкләү | ел саен | МәгБ,<br>ЯЭСТБ, МәдБ |
| 1.15 | «Хезмәткә һәм оборонага әзер» Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы чараларын оештыру һәм үткәрү | даими | ЯЭСТБ |
| | **2. Массакүләм спортны үстерү** | | |
| 2.1 | Пенсионерлар арасында «Өченче яшь» Спартакиадасын үткәрү | 2019-2021еллар | ЯЭСТБ, СЯБ |
| 2.2 | Район Советы һәм Башкарма комитеты хезмәткәрләре Спартакиадасы | 2019-2021еллар | ЯЭСТБ |
| 2.3 | Предприятиеләр һәм оешмалар арасында традицион Спартакиада командалары һәм катнашучылары санын арттыру | 2019-2021еллар | ЯЭСТБ |
| 2.4 | Яшәү урыны буенча һәм массакүләм ял итү урыннарында халык белән традицион һәм даими спорт-массакүләм чараларын оештыру | район спорт-массакүләм чараларының календарь планы буенча | ЯЭСТБ |
| 2.5 | Район укучылары арасында Спартакиаданы гамәлгә кертү һәм үткәрү | 2019-2021еллар | ЯЭСТБ |
| 2.6 | Районның мәктәпкәчә оешмалары арасында Спартакиаданы | 2019-2021еллар | ЯЭСТБ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | гамәлгә кертү һәм үткәрү | | |
| 2.7 | Район мәгариф оешмаларында һәм предприятиеләрендә «Сәламәтлек көне» үткәрү | 2019-2021еллар | МәгБ, предприятияләр, оешмалар |
| 2.8 | Ишегалды спорты төрләрен үстерү (стритбол, «Кўн туп», «Алтын алка» һ. б.) | 2019-2021еллар | ЯЭСТБ |
| 2.9 | Мәгариф оешмалары укучыларының «Мәктәп Лигасы», «Президент ярышлары» ярышларында катнашуы | 2019-2021еллар | ЯЭСТБ, МәгБ |
| **3. Сәламәтлек саклау органнары белән үткәреләсе чаралар** | | | |
| 3.1 | Район хастаханәсе базасында спортчылар һәм укучы яшьләр өчен медицина күзәтүен оештыру | даими | ҮРХ, СЯБ, ЯЭСТБ |
| 3.2 | Спорт-массакүләм чаралар барышында бушлай медицина хезмәте күрсәтүне тәэмин итү | даими | ҮРХ |
| 3.3 | Укучыларның сәламәтлек паспортын алып бару | 2019-2021еллар | МәгБ |
| **4. Өлкәннәр һәм инвалидлар спортын үстерү** | | | |
| 4.1 | Физик культура һәм сәламәтлекне ныгыту өлкәсендә аларның мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү өчен элеккеге спортчылар, тренерлар физик культура укытучылары арасыннан спорт ветераннары клубын төзү. | 2019-2021еллар | ЯЭСТБ |
| 4.2 | Инвалид балалар белән физкультура-сәламәтләндерү эшен үткәрү, республика ярышларында һәм спартакиадаларда катнашу | аерым план буенча | ЯЭСТБ, ҮРХ, СЯБ |
| 4.3 | Массакүләм мәгълүмат чараларын ветераннарның һәм инвалидларның физик культура һәм спорт белән актив шөгыльләнүләре турындагы хәбәрләр белән тәэмин итү | даими | «Заря», «Таң» газетасы |
| 4.4 | Мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр арасында Спартакиаданы гамәлгә кертү һәм үткәрү | 2019-2021еллар | ЯЭСТБ |
| 4.5 | Мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен спортзалларга ташламалы рәвештә йөрү мөмкинлеге кертү | 2019-2021еллар | ЯЭСТБ |
| **5. Матди-техник базаны үстерү** | | | |
| 5.1 | Мәгариф учреждениеләрендә спорт шәһәрчекләрен һәм балалар өчен уен мәйданчыкларын яңарту һәм төзү | даими | МәгБ |
| 5.3 | 120 кешегә исәпләнгән стационар бөтенсезон балалар сәламәтләндерү лагере төзелеше | 2019-2021еллар | РБК |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5.4 | Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбенең матди-техник базасын ныгыту - 1 нче номерлы СКын ремонтлау | 2019-2021еллар | РБК |
| 5.5 | Район мәгариф системасының спорт базасын ныгыту (район мәктәпләренең спорт залларын ремонтлау) | даими | МәгБ, РБК |
| | **6. Спорт төрләрен үстерү өстенлекләре** | | |
| 6.1 | Район спортчыларының югары нәтиҗәләргә ирешкән спорт төрләрен үстерүгә мөмкин кадәр ярдәм итү (бадминтон, ирекле көрәш, билбау көрәше, баскетбол, чаңгы ярышлары, волейбол, өстәл теннисы, хоккей һ.б.).<br>Спорт төрләрен кертү һәм үстерү (шашка, шахмат, бокс, мини-футбол, йөзү, спорт ориентлашуы һ. б.)<br>Спорт секцияләренең матди-техник базасын ныгыту. | даими | ЯЭСТБ |
| 6.2 | Йөзү бассейныннан файдалану һәм халыкны сәламәтләндерү нәтиҗәлелеген арттыру максатларында халыкның аерым категорияләре өчен ташламалы абонементлар кертертү һәм медицина тикшерүе системасын гадиләштерү (бассейнга йөрүче кешеләрне визуаль карау). Белем бирү оешмаларында 2-нче номерлы СКк түләүсез йөрүне кертү. | 2019-2021еллар | МәгБ, ЯЭСТБ |
| 6.3 | Укыту-күнегүләр процессын яхшырту өчен өстәмә финанслау җәлеп итү. | 2019-2021еллар | ЯЭСТБ |
| 6.4 | Районда яңа спорт төрләрен үстерү | 2019-2021еллар | РБК, ЯЭСТБ |
| | **7. Кадрлар белән тәэмин итү** | | |
| 7.1 | Физик культура һәм спорт өлкәсендә белгечләр турында мәгълүматлар банкын булдыру һәм яңарту. | даими | ЯЭСТБ |
| 7.2 | Югары сыйныф укучылары арасында югары спорт нәтиҗәләренә ирешкәннәре белән һөнәри юнәлеш бирү эшен алып барырга һәм Республиканың махсуслаштырылган уку йортларына кергәндә аларга ярдәм күрсәтү | 2019-2021еллар | ЯЭСТБ, МәгБ |
| 7.3 | Массакүләм спорт чараларын планлаштыру тәҗрибәсен алмашу һәм гомумиләштерү буенча семинарлар, ачык дәресләр, киңәшмәләр үткәрү, аларның республика семинарларында һәм конкурсларында катнашуын тәэмин итү | аерым план буенча | МәгБ, ЯЭСТБ |
| 7.4 | Тренер-укытучыларның, шулай ук спорт буенча яшь | 2019-2021г.г. | МәгБ, ЯЭСТБ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | квалификацияле белгечләрнең тормышы һәм эше өчен уңай социаль шартлар тудыру | | |
| 7.5 | Физик культура, спорт һәм туризм хезмәткәрләрен яңадан әзерләүне һәм квалификацияләрен күтәрүне оештыру, спорт һәм туризм төрләре буенча инструкторлар, тренерлар һәм судьялар, гидлар әзерләү | 2019-2021г.г. | ЯЭСТБ, МәгБ |

**Шартлы билгеләмәләр:**

**Район Советы (РС), Мәгариф Бүлеге (МәгБ), Мәдәният Бүлеге (МәдБ), Яшьләр Эшләре, Спорт һәм Туризм Бүлеге (ЯЭСТБ), Мәшгульлек Үзәге (МҮ), Башкарма комитетның инфраструктур үсеш бүлеге (ИҮБ), Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге (ЭЭМБ), Социаль Яклау Бүлеге (СЯБ), Алексеевск Аграр Көллияте (ААК), «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАСУ (РҮХ), «Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Алексеевск районындагы бүлеге» (ХКБ), Авыл Җирлекләре (АҖ), Алексеевск шәһәр җирлеге (АШҖ), «Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия» (ББК), Район башкарма комитеты (РБК), «Салават күпере» «гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәге» (ГСЯҮ), район инвалидлар җәмгыяте (ИЖ), Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитеты (ШЖ), Үзәк китапханә системасы (ҮКС), "Заря"," Таң" район газетасы ("Таң").**

**Башкарма комитет эшләре**
**белән идарә итүче** **Г.А.Юсупова**